***Тема:*** Антонимнар. 5 нче сыйныф өчен.

***Максат:***

*1.* Антонимнар төшенчәсен актуальләштерү,аларның сөйләмдәге әһәмиятен ачыкларга ярдәм итү.

2.эзлекле фикер һәм иҗади сәләтне үстерү.

3.халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләр аша әхлаклылык тәрбияләү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

**Танып-белү УУГ:** кирәкле мәгълүматны эзләп табу, сорауларга җавап бирү, уй-фикерне аңлап һәм ирекле оештыру;

**Коммуникатив УУГ:** үз фикереңне тиешле дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;

**Регулятив УУГ:** яңа мәгълүмат алырга омтылу, үз фикереңне төгәл җиткерә белү, өйрәнгәннәрне истә тотып үз белемеңә, үз эшеңә бәя бирү.

**Шәхси нәтиҗәләр:** уку һәм сөйләмне камилләштерү, парлап эшләгәндә бер-береңә игътибарлы булу, җаваплылык хисе тәрбияләү.

**Дәрес төре:**Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

**Предметара бәйләнеш:** татар теле һәм әйләнә-тирә дөнья.

**Эш төрләре (алымнар):** сорау-җавап, карточкалар белән эш, проблемалы сорау, сүзлек белән эш, төркемнәрдә эшләү, синквейн, һ.б.

**Җиһазлау:**дәреслек Хәсәншина Р.Г.,интерактив такта, ноутбук,”Антонимнар”сүзлеге, ”Табышмаклар”китабы, карточкалар.

***Дәрес барышы:***

**I.Мотивлаштыру-ориентлашу.**

1.а)Уңай психологик халәт тудыру;

Хәерле көн, укучылар,!
Кәефләрне күтәрик,
Дусларча бер елмаеп,
Бер-беребезгә
Хәерле көннәр телик!

Уң һәм сул як иптәшләрегез белән, йөзгә-йөз иптәшләрегез белән исәнләшегез.

-Укучылар,үткән дәреснең уку мәсьәләсен искә төшерегез.(алдагы дәрестә”Синонимнар”темасын өйрәндек) Релли Робин структурасы.

***II.Уку мәсьәләсен кую ситуациясе.***

-Укучылар, тәрәзәгә күз салыйк әле,бүген нинди матур көн!Соклангыч, шулай бит?Ә кичәге көн бүгенгедән аерыла идеме?

-җаваплар

-Әйе,еш кына без бу үзгәрешләрне сизмибез дә.Менә сезнең янга килгәндә,минем күңелемә менә мондый әкият килде.Тыңлап карагыз әле,әкияттә нинди гадәттән тыш вакыйгалар бар икән?(Әкият укыла)

Борын-борын заманда
Ерак түгел Казаннан

Яшәгән ди кешеләр -
Бары да бер ишеләр.
Сәер булган ди алар:
Тумаган-үлмәгәннәр,
Еламый- көлмәгәннәр,
Йокламый-тормаганнар.
Мәктәпкә бармаганнар,
Өйгә дә кайтмаганнар,
Бик күңелсез ди монда:
Көн дә юк ди, төне дә
Гел бер төрле гомергә,
Шуңа күрә бу кешеләр
Яшь тә, карт та түгел ди,
Бу җирдә күптәннән инде
Яз да, көз дә булмый ди,
Кар да юк, ди- чирәм дә,
Эссе дә, салкын да түгел.
Уйлап карыйкмы бергә-
Ниләр җитми бу илгә?

Укучылар, бу ил кешеләренең яшәве нигә кызык түгел икән?

• Җаваплар.

-Әйе,чөнки монда капма-каршылыклар юк.Гел бертөрлелек тасвирлана.Бертөрлелек туйдыра,ялкыта,кызык булмый.Укучылар,капма-каршылыклы мәгънәле сүзләрне табыйк әле.

Без бүген төркемнәрдә эшләрбез.Һәр эшкә үзбәя куеп барырсыз.(2 төркем дә тактага чыгып,капма-каршы мәгънәле сүзләрне язалар)

Дөрес,ә безнең тормышыбызда капма-каршылыклар бармы?

Җаваплар.

Бүгенге дәреснең уку мәсьәләсе нинди ?

Антонимнар-грекча-антик-каршы,опута-исем.Үзбәя.

Тема тактага һәм дәфтәргә языла.

1 слайд-Антонимнар-капма-каршы мәгънәле сүзләр.Мисалларны укыйбыз.

2 слайд-Антонимнарның мәгънәләре.Үзбәя.

Физкультминут.Су өстендә бакалар
Баталар да,калкалар(2)
Уңга да иеләләр
Сулга да иеләр
Һәм бер урында сикерешеп алалар.

Үзбәя.

Тема тактага һәм дәфтәргә языла.

**III.УМ адымлап чишү.**

Мин сезгә карточкалар бирәм,антонимнары иптәшләрегездә.Сүзне укыгач,антонимы булган кеше торып басарга тиеш.

1.471 нче күнегү.Антонимнарга билгеләмә бирергә,өстәмә мисаллар белән дәлилләргә.Аларның сөйләмдә әһәмияте нинди? ФИНК-РАЙТ-РАУНД РОБИН структурасы.

2.Модельләштерү.(төркемнәрдә эшлиләр)

*Көтелгән җавап:Капма-каршы мәгънәле сүзләр **антонимнар** дип атала.Мәсәлән:әкрен-тиз,көн-төн,яз-көз һ.б.Антонимнар, синонимнар кебек үк,сөйләмне баета,образлы итә.Әдәби әсәрләрдә чагыштыру,каршылык тудырырга ярдәм итәләр.*

-*капма-каршы* мәгънәле сүзләр

-сөйләмне баета,образлы итә

Үзбәя.

***IV.Ныгыту**.*

2.472 нче күнегү. Бирелгән фигыль,сыйфат,рәвешләрнең антонимнарын уйлап язарга.

*Көтелгән җавап:Я*п,куш,төш,тап,йокла,уты*р;киң,якты,кичке, тәбәнәк,иске,әдәпсез;бүген,быел,җәен,монда,аз,(әз),чынлап(чын).*

Үзбәя.

3.473 нче күнегү.Антоним парларны кулланып төзелгән мәкальләр уйлап язарга.

*Көтелгән җавап:**Бер** егетнең кыюлыгы **мең** егеткә дан китерә.Кыю **бер** үләр,куркак **мең** үләр.Хезмәтнең тире **ачы** булса да,җимеше **татлы.**Иң **ачы** нәрсә дә тел,иң **татлы** нәрсә дә тел.**Төче** ялганнан **ачы** хакыйкать яхшы.Сүздә **бар**,эштә **юк.Ихтыярлы** кеше-**бар** кеше,**ихтыярсыз** кеше-**юк** кеше.Үзең **кыек** утырсаң да,сүзең **туры** булсын.**Ач** кадерен **тук** белми.*

Үзбәя.

Искәрмә: Укучылар авырсынса,укытучы мәкальнең бер өлешен әйтә,укучылар дәвамын яза.

4.474 нче күнегү.Дәреслектәге кагыйдәгә таянып,даими һәм контекстуаль антонимнарны билгеләргә.

*Көтелгән җавап:Даими антонимнар:югарыга-түбәнгә,үрнәк-гыйбрәт,ачы-төче.*

*Контекстуаль антонимнар:кош-кеше,канат-дуслык,энҗе чәчәк ләр-әрем,филдәй-чыпчык тезеннән.*

Үзбәя.

Антонимнар ни өчен кулланыла?(слайд)

**V.Рефлексия, бәяләү.**

1.”Дәрестә нинди УМ чиштек?” соравына җавап бирү.
2.Нәрсәләр белдегез?
3.Дәрескә гомуми бәя кую.

**VI.Өйгә эш бирү.**

**Укытучы:**Сезгә 3 вариантта өй эше тәкъдим итәм.Берсен сайлап эшләгез.

475 нче күнегү;

Н.Исәнбәтнең “Татар халык табышмаклары” китабыннан антонимнар кергән 4-5 табышмак сайлап языгыз.

Антонимнар кертеп, шаян табышмаклар уйлап языгыз.

- Дәрестә актив катнашуыгыз өчен рәхмәт! Дәрес тәмам, чыгарга мөмкин.